Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«24» октябрь 2019 ел №89

Территорияне межалау проектын
әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2019 елның 17 октябрендәге 8228нче номерлы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия бәяләмәсе нигезендә, Абдуллин Тимур Марсель улы мөрәҗәгате нигезендә,

ӘЛМӘТ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. Абдуллин Тимур Марсель улына үз акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Объездная тракты адресы, кадастр номеры 16:45:0504:6041 булган җир кишәрлегенә карата 5526 кв.м мәйданлы территорияне ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. «Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе турындагы әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А. А. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.Н. Гирфанов